# КАРАР

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге составына керүче Ромодан авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**16 декабрь 2021 е.** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә 2021 елның 16 декабрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Ромодан авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау;
- урамнарны яктыртуны карап тоту;
- тракторны карап тоту;

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә ярашлы рәвештә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 239 катнашучысы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының ___ катнашучысы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенның ___ катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге составына керүче Ромодан авылындагы этаплап гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. Сорау буенча карарны танырга: «Ромодан авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;

- су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау;

- урамнарны яктыртуны карап тоту;

- тракторны карап тоту;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Ромодан авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә».

3. Әлеге карарны Ромодан авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге Ромодан мәдәният йорты бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Ромодан авылы, Яшьләр ур., 15 А й.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Ромодан авыл җирлеге башлыгы** **И.А.Чекалина**